СОВЕТ УСАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ҮСӘЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 1-41

Карар
от 29.04.2019 г.

“Усали авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-31 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге”муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Советы карары турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ санлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Мамадыш районы прокуратурасының 2019 елның 26 февралендәге тәкъдимнәре ,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Усали авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-31 санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә(17.09.2018 ел, 2-35 нче санлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.Кагыйдәләрнең 2 бүлегенең 13 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 56 пункт белән тулыландырырга:

“ 56. Юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) һәм физик затлар Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үзләренең милкендә биләүдә

яки кулланууда булган җир участокларында Сосновский балтырганын бетерү (юк итү), аннан арындыру, бетерү (юк итү) буенча мөстәкыйль рәвештә үз хисабына системалы чаралар үткәрергә тиеш, (Сосновский балтырганын бетерү (юк итү) буенча чаралар алар бөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганга кадәр үткәрелергә тиеш)".

1.2. Кагыйдәләрнең 3 бүлегендәге 26 нчы бүлекнең 171 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча белән тулыландырырга:

"Сосновский балтырганының таралу чыганакларын ачыклау, үз милекләрендә булган җир кишәрлекләрендә бетерү (юк итү), буенча чаралар юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) һәм физик затларның үз акчалары хисабына мөстәкыйль рәвештә Сосновский балтырганы бөреленгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш."

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башлыгына А.И.Зиатдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /А.И.Зиатдинов/